ЧӘРШӘМБЕ
17 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 89 (5889)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ҖИРДӘН ТУЛЫ ҺӘМ ДӨРЕС ФАЙДАЛАНЫЙК

Безнең ил кин, бай һәм гүзәл. Нәрсә генә чәчелми, нәрсә генә үсми, нәрсә генә уңмый безнең ил кырларында! Җир—Октябрь Социалистик революциясе яулап алганнарның иң әһәмиятлеләреннән берсе. Җир—ул, колхозларның байлык чишмәсе. Революция нәтиҗәсендә үзенең чын хуҗалары кулына күчкән җир чәчәк ата торган байлык бакчасына әйләнде. Менә бу бакчаның һәрбер түтәле, һәрбер буразнасы колхозчылар тарафыннан зур мәхәббәт белән эшкәртелергә тиеш. Колхоз басулары ил өчен продуктлар күпме кирәк булса, шул кадәр җитештерә торган чыганак булырга тиеш!

ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасындагы үзгәрешләр турындагы һәм дәүләткә мәҗбүри рәвештә ашлык тапшыру турындагы карарлары җирдән әнә шулай тулы һәм яхшы файдалануны, колхозлар һәм дәүләт интересларын күз алдында тоталар. Бу карарлар авыл хуҗалыгын яңа баскычка күтәрү идеясе белән сугарылганнар. Аларда партия һәм хөкүмәтнең колхоз строе турында аеруча кайгыртучанлыгы гәүдәләнә.

Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү, аерым алганда дәүләткә ашлык тапшыру политикасындагы үзгәрешнең асылы нәрсәдән гыйбарәт соң?

ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм Союз Совнаркомының 1940 нчы ел, 11 нче апрель карары буенча колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык тапшыруларының әлегә чаклы яшәп килгән тәртибе бетерелә. Әгәр дә элек дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыклар тапшыру бу культураларның чәчү планнары буенча исәпләнсә, **1940 нчы елгы уңыштан башлап колхозлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыкны колхозларга беркетелгән сөрү җирләренең (пашня) һәрбер гектары исәбеннән тапшырачаклар.**

Ашлык тапшыруга карата булган үзгәрешнең асылы әнә шуннардан гыйбарәт. Димәк, ашлык тапшыруның күләме әлегә чаклы булганча чәчү планына карап түгел, бәлки сөрү җирләренең һәрбер гектары исәбеннән булачак. Шунлыктан, сөрергә яраклы булган барлык җирләрне тулысынча эшкәртү белән кызыксыну һәрбер колхоз алдына конкрет рәвештә килеп баса. Ә сөрергә яраклы барлык җирләрне тулысынча эшкәртү, файдалану—ул чәчү мәйданнарын тагын да киңәйтү, ашлык өчен көрәшне тагын да көчәйтү, дәүләт һәм колхоз интереслары өчен иҗад инициативасын тагын да үстерү дигән сүз.

Безнең Татарстан колхозларында яңадан үзләштерергә мөмкин булган җирләр бармы соң? Әйе, бар һәм күп. Татарстанда 110 мең гектар куаклык, 62 мең гектар сазлык (болота) җир исәпләнә, куаклыкларның 93 мең гектары, сазлыкларның 49 мең гектары колхозлар карамагында. Җирнең кадрен белгәндә, барлык җирләрне тулысынча файдалану өчен чын хуҗаларча кайгыртканда бу сазлык җирләрне һәм куаклыкларны эшкәртергә бик мөмкин һәм кирәк. Кайбер колхозлар, мәсәлән, Әгерҗе районының Каганович исмендәге колхозы, Әтнә районының Киров һәм Куйбышев исмендәге колхозлары бу эшне башлап та җибәрделәр инде. Киптерелгән сазлык җирләрне көтү йөртү өчен һәм печән чәчү өчен файдаланалар. Бу турыда башка колхозларда да уйлашырга бик вакыт.

Татарстанда файдаланылмыйча ташландык хәлдә ята торган җирләр югарыда күрсәтелгәннәрдән тыш та күп. Ташлы, комлы, чокыр, солончак (тозлы) дип йөртелә торган җирләр генә дә 165 мең гектар исәпләнә, шуның 118 мең гектары колхозларда. Татарстан кебек илнең үзәгендәге өлкәдә бу кадәр җирнең әрәм булып ятуы, ул просто җинаят! Колхозлардагы көч бу җирләрне дә буйсындырырга җитәрлек. Җирнең һәрбер вершогы яхшылап тәрбияләнергә һәм файдаланырга тиеш.

Партиянең район оешмалары һәм җир органнары, яңа җирләрне үзләштерүче колхозларга хөкүмәт тарафыннан ясала торган льготалар турында ныклап аңлатырга тиешләр. Сөрелми яткан җирләрне (чирәмнәрне) яңадан сөргән, сазлыкларны киптергән һәм куаклыкларны арчыган колхозлар бу җирләр өчен мәҗбүри ашлык тапшыруга үзләштерүнең икенче елында гына тартылулары турында һәрбер колхозчы белергә тиеш.

Билгеле, колхозларның орлыкчылык хуҗалыгын ныгыту мәсьәләсе сөрергә яраклы яңа җирләрне үзләштерү белән генә чикләнми. Эш, „җирдән алырга мөмкин булган нәрсәнең барсын да алу“ да тора. Җир никадәр яхшы эшләнсә, никадәр яхшы тәрбияләнсә, ул уңышны шул кадәр күп бирер, авыл хуҗалыгы продуктлары шул кадәр мул булыр.

Бу тәләккә быел ук ирешү өчен, иң элек, Татарстан колхозларында игеп уңышы буенча артта калуны бетерергә кирәк. Язгы чәчүне яхшы сыйфат белән иң кыска срокта үткәрү, игеп уңышын күтәрү өчен таза фундамент салу булачак. Партия һәм хөкүмәт карарларын тормышка ашыруга эш белән, язгы чәчүне яхшы үткәрү белән җавап бирергә кирәк. Югары уңыш өчен көрәш нак менә хәзер—яз көне хәл ителә.

Колхозларның һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык тапшырулары турындагы закон буенча советларның һәм партиянең край, өлкә комитетлары өстенә дә зур эш йөкләтелә. Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык тапшырулары буенча район өчен еллык нормалар билгеләү эше автономияле республикаларда Совнаркомнар һәм Өлкә Комитетларына йөкләтелде. Димәк, бу тармакта гаять зур һәм катлаулы бурыч тора. Еллык нормалар билгеләү кыска вакыт эчендә башкарылырга һәм СССР Совнаркомы янындагы Экономсовет раслаганнан соң, Татарстанда 1940 нчы елның 1 нче июненә игълан ителергә тиеш.

Татарстан колхозчылары, Советлар Союзының барлык колхозчы крестьяннәре кебек үк, бу карарларны зур дәрт белән каршы алдылар һәм алар игеп уңышын күтәрүдә, чәчү мәйданнарын киңәйтү өчен яңа җирләрне үзләштерүдә дә беренче сафларда барырлар, кардәш өч республика ярышында алдынгылыкны яулап алырлар!

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Карел-Фин ССР дан СССР Верховный Советына депутатлар сайлау көне турында

1. Карел-Фин ССР дан СССР Верховный Советына депутатлар сайлауны 1940 нчы елның 16 нчы июненә билгеләргә.

2. Карел-Фин ССР дан СССР Верховный Советына депутатлар сайлау кампаниясе 1940 нчы елның 16 нчы апреленнән башлана дип игълан итәргә.

*СССР Верховный Советы Президиумы Председателе **М. КАЛИНИН.***
*СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре **А. ГОРКИН.***

Москва, Кремль. 15 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Союз Советына сайлаулар буенча Випури (Выборг) сайлау округы төзү турында

СССР Конституциясенең 34 нче статьясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение“ нең 21, 23 һәм 24 нче статьяләре нигезендә Союз Советына сайлаулар буенча 613 нче номерлы Випури (Выборг) сайлау округы төзергә. Үзәге—Випури (Выборг) шәһәрендә. Аның составына түбәндәге өязләр керә: Сяккиярви һәм Иоханнес волостьларын кертеп Випури өязе, Ияски, Кякисальми (Кексгольм), Куркийоки өязләре, Вяртсиля пунктын кертеп Сортавала (Сердоболь) өязе һәм Лиусваара һәм Куолисмаа пунктларын кертеп Сальми өязе.

*СССР Верховный Советы Президиумы Председателе **М. КАЛИНИН.***
*СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре **А. ГОРКИН.***

Москва, Кремль. 15 апрель, 1940 ел.

Бөртекле, кузаклы, ярмалы культураларны, дөгене һәм майлы культураларны эшкәрткән өчен көрәк оны алуны бетерү турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары

Колхозлар һәм җирле Советлар кулындагы тегермәннәрнең эшен яхшырту, колхозларга һәм колхозчыларга җиңеллек тудыру һәм ашлыкның азык һәм фураж керемнәре өчен бөртекле ашлыкны тартуны һәм майлы культураларны эшкәртүгә колхозларның кызыксынуларын арттыру теләге белән ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

1. Дәүләтнең, колхозларның һәм кооперативларның барлык тегермәннәрендә, ярма яргычларында һәм май заводларында бөртекле, кузаклы, ярмалы культураларны, дөгене һәм майлы культураларны эшкәрткән өчен дәүләт доходына керә торган, натуралата көрәк оны түләтүне 1940 нчы елның 1 нче июленнән бетерергә һәм бу культураларны эшкәрткән өчен акчалата түләү кертергә.

2. Союзный һәм автономияле республикаларның халык комиссарлары советларына, край һәм өлкә башкарма комитетларына,—колхозларның дәүләткә бөртекле ашлык тапшырулары буенча районнар өчен нормалар билгеләгәндә, элекке вакытта колхозчылардан көрәк оны буенча дәүләт алып килгән күләмдәге бөртекле ашлыкны һәм көнбагышны колхозчылардан аласы урында колхозлардан алырга кирәклекне искә алырга такдим итәргә.

3. Колхозлар кулындагы тегермәннәрдә, ярма яргычларда һәм май заводларында бөртекле, кузаклы, ярмалы культураларны, дөгене һәм майлы культураларны эшкәрткән өчен акчалата түләүне, союзный республикаларның халык комиссарлары советлары карарларында билгеләнгән чикләрдә, колхоз правлениеләре, ә җирле Советлар кулындагы тегермәннәрдә, ярма яргычларда һәм май заводларында—хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары билгелиләр.

4. Колхозларга үзләренең тегермәннәрен, бигрәк тә су һәм җил тегермәннәрен булдырырга, бар кадәр тегермәннәрне төзәтергә һәм тулы тәртипкә китерергә, ә урыннардагы совет һәм партия органнарына бу эштә колхозларга кирәгенчә булышлык күрсәтергә такдим итәргә.

5. Тегермәннәре, ярма яргычлары һәм май заводлары булган дәүләт, кооператив оешмаларын һәм колхозларны,— бөртекле ашлык һәм көнбагыш буенча 1940 нчы елның 1 нче июленә кадәр кергән барлык көрәк онын, шушы карар чыкканчыга кадәр булган шартларда түләү белән, 1940 нчы елның 10 нчы июленнән дә соңга калмыйча Заготзерноның хәзерләү пунктларына тапшырырга мәҗбүр итәргә.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре И. СТАЛИН.

15 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Карел-Фин ССР дан Милләтләр Советына сайлаулар буенча сайлау округлары төзү турында

СССР Конституциясенең 35 нче статьясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение“ нең 22, 23 һәм 24 нче статьяләре нигезендә Милләтләр Советына сайлаулар буенча түбәндәге сайлау округларын төзергә:

Октябрь сайлау округы № 587 (үзәге—Петрозаводск шәһәре).
Петрозаводск шәһәренең Октябрь районы.

Зарецкий сайлау округы № 588 (үзәге — Петрозаовдск шәһәре).
Петрозаводск шәһәренең Зарецкий районы.

Первомайский сайлау округы № 589 (үзәге — Петрозаводск шәһәре).
Петрозаводск шәһәренең Первомайский районы һәм Соломенное эшчеләр поселкысы.

Прионега сайлау округы № 590 (үзәге—Петрозаводск шәһәре).
Прионега һәм Шелтозеро районнары.

Пряжа сайлау округы № 591 (үзәге—Пряжа авылы).
Пряжа һәм Ведлозеро районнары.

Олонец сайлау округы № 592 (үзәге—Олонец авылы).
Олонец районы.

Кондопога шәһәр сайлау округы № 593 (үзәге— Кондопога шәһәре).
Кондопога шәһәре, Сунский эшчеләр поселкысы һәм Кондопога районының Горский, Кондопога, Янишполь, Кулмук һәм Новинский авыл советлары.

Кондопога авыл сайлау округы № 594 (үзәге—Кондопога шәһәре).
Кондопога районының Вороновский, Сопохский, Сележский, Тивдийский, Илемсельгский, Лижемский, Кяллесельгский һәм Уницкий районнары һәм Петровский районы.

Заонега сайлау округы № 595 (үзәге—Шуньга авылы).
Заонега районы.

Пудож сайлау округы № 596 (үзәге—Пудож авылы).
Пудож районы.

Медвежьегорск шәһәр сайлау округы № 597 (үзәге—Медвежьегорск шәһәре).
Медвежьегорск шәһәре һәм Медвежьегорск районының Лумбуш, Чебинский, Дусильгский һәм Покровский авыл советлары.

Медвежьегорск авыл сайлау округы № 598 (үзәге—Медвежьегорск шәһәре).
Повенец эшчеләр поселкысы һәм Медвежьегорск районының Римский, Кодозеро, Челмужский, Лобский, Даниловский, Морско-Масельский, Вожмосалмский, Выгозеро һәм Койкиницкий авыл советлары.

Сегозеро сайлау округы № 599 (үзәге—Масельская эшчеләр поселкысы).
Сегозеро районы, Медвежьегорск районының Масельская һәм Сегежа эшчеләр поселоклары һәм Уросозера авыл советы.

Ругозеро сайлау округы № 600 (үзәге—Ругозеро авылы).
Ругозеро, Реболы һәм Тунгуд районнары.

Беломорск шәһәр сайлау округы № 601 (үзәге—Беломорск шәһәре).
Беломорск шәһәре һәм Беломорск районының Шиженский, Сухонаволокский һәм Виремский авыл советлары.

Беломорск авыл сайлау округы № 602 (үзәге—Беломорск шәһәре).
Беломорск районы. (Беломорск шәһәре һәм Шиженский, Сухонаволокский һәм Виремский авыл советлары керми).

Кемь шәһәр сайлау округы № 603 (үзәге—Кемь шәһәре).
Кемь шәһәре һәм Рабочеостровск эшчеләр поселкысы.

Кемь авыл сайлау округы № 604 (үзәге—Кемь шәһәре).
Кемь районы (Кемь шәһәре һәм Рабочеостровск эшчеләр поселкысы керми), Калевалы районы.

Лоухи сайлау округы № 605 (үзәге—Лоухи авылы).
Куолаярви шәһәре һәм Куолаярви районындагы барлык пунктлар һәм Лоухи, Кестеньгский районнары.

Випури (Выборг) шәһәр сайлау округы № 606 (үзәге Випури (Выборг) шәһәре).
Випури (Выборг) шәһәре.

Випури (Выборг) авыл сайлау округы № 607 (үзәге—Випури (Выборг) шәһәре).
Випури өязе (Саккаярви һәм Иоханнес волостьларын кертеп) һәм Иявки өязе.

Кякисальми (Кексгольм) сайлау округы № 608 (үзәге—Кякисальми (Кексгольм) шәһәре).
Кякисальми (Кексгольм) өязе.

Сортавала (Сердоболь) сайлау округы № 609 (үзәге—Сортавала (Сердоболь) шәһәре).
Сортавала (Сердоболь), Куркпийский өязләре (Вяртсиля пункты да керә).

Питкяранта сайлау округы № 610 (үзәге—Сальми шәһәре).
Сальми өязенең Сальми, Импилахти, Суйстамо, Соанлахти волостьлары.

Суоярви сайлау округы № 611 (үзәге—Суоярви шәһәре).
Сальми өязенең Суоярви һәм Корписелькя волостьлары (Лиусваара һәм Куолисмаа пунктлары да керә).

*СССР Верховный Советы Президиумы Председателе **М. КАЛИНИН.***
*СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре **А. ГОРКИН.***

Москва, Кремль. 15 апрель, 1940 ел.

Юдино депосы машинисты иптәш В. В. Герасимов, Беренче Май алды ярышына кушылып, үзенең паровозында тәүлегенә 500 километрдан артык йөрүгә ирешә. В. Лужбин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ БАРЛЫК РАЙОН ҺӘМ АВЫЛ СОВЕТЛАРЫНА

Илебездә социализм тәмам һәм бөтенләйгә җиңде. Совет авылының бөтен тормышы үзгәрде. Колхозлар ныгыдылар. Авыл хуҗалыгының йөз меңнәрчә гүзәл мастерлары үсте. Гүзәл социалистик хезмәт үрнәкләре өчен аларның күбесе хөкүмәт тарафыннан бүләкләнде. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе безнең бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләребезне, безнең иң яхшы кешеләребезне—социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларын бөтен илгә, бөтен дөньяга киң рәвештә күрсәтте.

Колхоз строе авылда чын культура революциясе өчен нигез корды. Хәзер безнең алда колхозчыларның бөтен массасына алдынгылар белән бер сафка басарга булышлык итү бурычы тора. Хәзер культура-тәрбия эше моңарчы булганга караганда да ныграк кирәк.

Советларда моны эшләү өчен гаять бай мөмкинлекләр бар. Бездә ныклы экономик база, йөз меңнәрчә культура-агарту учреждениеләре—мәктәпләр, уку өйләре, клублар, көтепханәләр, культура йортлары бар. Авылның җәмәгать һәм культура тормышында дәрт белән катнашучы гүзәл, үзенең Ватанына чын күңелдән бирелгән совет интеллигенциясе бар.

Илебез тиз алга бара. Культура эше илнең хуҗалык-политик үсешеннән артта калмаска тиеш. Шунлыктан үткән заманның хурлыклы мирасы булган укый-яза белмәүчелекне күп кенә авыл Советларының әле һаман да бетермәүләре белән килешергә мөмкин түгел.

Уку өенең, клубның, культура йортының, көтепханәнең начар эшләвенә хезмәт ияләре депутатларының җирле Советының игтибар бирми каравы белән, алар турында кайгыртмавы белән килешергә мөмкин түгел.

Авылның политик-агарту органнарын—уку өйләрен, колхоз клубларын, культура йортларын ныгыту өчен барын да эшләргә кирәк. Колхозчылар үзләренең буш вакытларын культуралы шартларда канәгатләнеп үткәрә алсыннар өчен, үзлекләреннән белем алырга, радио тыңларга, үзләренең колхоз хорында, оркестрында, спектаклендә катнашырга мөмкинлекләре булсын өчен политик-агарту учреждениеләренең чиста, уңайлы биналары, яхшы җиһазлары булырга тиеш.

Һәрбер колхозчының үзен кызыксындыра торган һәр төрле сорауларга үз уку өенең белешмәләр өстәлендә аңлатмалар, җаваплар ала алуы, агротехника һәм башка түгәрәкләр булу, укытучының, врачның, агрономның лекцияләре, беседалары үткәрелү һәм яхшы китап, журнал, газета укырга мөмкинлек булдыру турында кайгыртырга кирәк.

Матбугат—китап, газета массаның культура ягыннан үсүе өчен гаять әһәмиятле урын тота. Советлар һәрбер уку өенең, колхоз клубының, культура йортының яхшы көтепханәсе булуга, газеталар һәм журналлар белән тәэмин ителүләренә, уку өендә әдәби кичәләр, кычкырып укулар үткәрелүгә ирешергә тиешләр.

Авылда яхшы уку өе, көтепханә, клуб—ул һәрбер Советның намус эше. Авылның бу культура учреждениеләре депутатларның көндәлек игтибары белән чолгап алынган булырга тиеш, авыл интеллигенциясе тарафыннан аларга һәр төрле булышлык һәм ярдәм күрсәтелергә тиеш.

Безнең хезмәт ияләре депутатларының яңа район һәм авыл Советлары, үзара ярышып, уку өйләрен, клубларны, культура йортларын кыска срок эчендә авылның чын культура учакларына әйләндерә алырлар, укый-яза белмәүчелекне якын вакыт эчендә бетерергә ярдәм итәрләр һәм шуның белән сайлаучылар алдындагы изге бурычларын үтәрләр, дип ышанам.

М. И. Калинин.

13 апрель, 1940 ел.

19 НЧЫ АПРЕЛЬ, КИЧ 6 СӘГАТЬТӘ, МЕНЖИНСКИЙ ИСМЕНДӘГЕ КЛУБТА

ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР АКТИВЫ ҖЫЕЛЫШЫ ЧАКЫРЫЛА.

КӨН ТӘРТИБЕ:

ВКП(б) Үзәк Комитетының чираттагы пленумының йомгаклары.

Билетлар ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты һәм шәһәр район комитетлары аркылы таратыла.

ВКП(б) ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМГӘ

ЛЕНИННЕҢ АПРЕЛЬ ТЕЗИСЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТАРИХИ ӘҺӘМИЯТЕ

Лениннең Апрель тезислары—большевизмның гаят зур документы, марксизм хәзинәсенә кыйммәтле вклад һәм социалистик революциянең җиңүе өчен көрәштә пролетариатның куәтле идея коралы булып торалар.

Россиядә буржуаз демократик февраль революциясе җиңгәннән соң туган катлаулы яңа обстановкада „партия бер селтәнү белән яңа юлга чыга алсын өчен Лениннең атаклы „Апрель тезислары" кирәк булды" (Сталин). Лениннең Апрель тезислары эшчеләр сыйнфына һәм партиягә көрәшнең яңа шартларында ориентировка бирделәр һәм социалистик революциягә күчү өчен көрәштә большевиклар партиясенә даһи план булып хезмәт иттеләр.

Солдат шинельләренә киенгән эшчеләр һәм крестьяннәр 1917 нче елның февралендә самодержавиене бәреп төшерделәр. Большевиклар партиясе подпольедән чыкты. Һәм аның күп кенә членнары ерак сөргеннәрдән кайттылар.

Революциянең беренче көннәрендә үк, большевиклар инициативасы белән, эшче һәм солдат депутатлары Советлары төзелде. Ләкин бу советларның күпчелегенә меньшевиклар һәм эсерлар кереп утырдылар.

Петроград Советының эсерлардан-меньшевиклардан торган җитәкчелеге властьны буржуазиягә бирү өчен барлык чараларны күрде. 1917 нче елның 27 нче февралендә эсер-меньшевик лидерларның турыдан-туры катнашы белән IV нче думаның председателе Родзянко җитәкчелегендә дәүләт думасының вакытлы комитеты төзелде. Эшче һәм солдат депутатлары Советы башкарма комитетының эсер-меньшевик лидерлары 2 нче мартта большевиклардан яшрен рәвештә сөйләшеп, князь Львов җитәкчелегендә вакытлы буржуаз хөкүмәт төзеделәр.

Ләкин буржуаз хөкүмәт белән бер рәттән тагын бер власть—эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең царизмга каршы союзы органы, пролетариат һәм крестьяннәр диктатурасы органы—эшче һәм солдат депутатлары советы яшәп килә иде. Шулай итеп илдә ике хөкүмәт төзелде, ике властьлылык килеп чыкты.

Большевиклар партиясе алдына вакытлы хөкүмәтнең империалистик характерын хезмәт ияләренә түземле рәвештә аңлату, соглашатель партияләрнең хыянәтләрен фаш итү бурычы килеп басты. Революцияне тагын да алга алып барырга һәм аның социалистик революциягә үсүен тәэмин итәргә кирәк иде.

1917 нче елның 12 нче мартында иптәш Сталин сөргеннән Петроградка кайтты һәм партия Үзәк Комитеты бюросының һәм „Правда" газетасының эшенә җитәкчелекне үз кулына алды. Иптәш Сталин речьләр, докладлар сөйли, „Правда" газетасына мәкаләләр яза, пролетариатның, большевиклар партиясенең бурычларын бөтен ачыклыгы белән күрсәтә. Ул, революцияне тагын да алга алып барырга кирәклекне һәм моның өчен эшчеләр белән крестьяннәрнең союзын ныгытырга, меньшевикларның һәм эсерларның массага йогынтысын бетерергә, ныклы оешмалар төзергә кирәклекне күрсәтте.

Шулай итеп, большевиклар партиясе Ленин директивалары һәм иптәш Сталин күрсәтмәләре рухында социалистик революциянең җиңүе өчен көрәш җәелдерде.

Хыянәтчеләр—Каменев, Рыков, Бубнов, Ногин һәм башкалар партиянең бу юлына каршы чыктылар.

Хыянәтче Каменев Россия пролетариатының социалистик революцияне тормышка ашыру өчен әле өлгереп җитмәгәнлеген, рус революциясенең буржуаз-демократик революция рамкаларыннан чыкмаска тиешлеген исбат итәргә маташты.

Большевиклар партиясе вакытлы хөкүмәткә ышанычсызлык белдерү политикасын яклады, оборончылыкка каршы чыкты һәм массаны солых өчен актив көрәшкә, империалистик талау сугышына каршы көрәшкә чакырды.

Ул вакытта Ленин Цюрихта иде һәм аннан директивалар, күрсәтмәләр җибәреп партиягә җитәкчелек итте. Аның атаклы „Ерактан хатлар" ы большевиклар партиясенә сугышчан хәрәкәт программасы булып хезмәт иттеләр.

„...Яңа хөкүмәткә **аз гына да** ышаныч һәм ярдәм күрсәтмәскә (Керенскийга, Гвоздевка, Чхенкелигә, Чхеидзега һәм аларның компаниясенә **аз гына да** ышаныч күрсәтмәскә) һәм **тагын да югарырак** этапны **коралланып көтеп торырга**, аның өчен **тагын да киңрәк базада коралы хәзерлек алып барырга**". (Ленин, том XX, бит 8).

Ләкин катлаулы обстановка хәрәкәткә турыдан-туры җитәкчелек итү өчен Лениннең үзенең Россиядә булуын таләп итте. Ләкин революцион Россиягә кайту җиңел түгел иде. Барлык юлларны үз кулларында тотучы Англия һәм Франция империалистлары Россиягә большевикларны һәм бигрәк тә Ленинне җибәрмиләр иде.

Ниһаят Ленин Германия аркылы Швециягә барырга рөхсәт ала. 26 нчы мартта Швейцариядән чыгып, ул 3 нче апрельдә Петроградка кайтып җитә.

Петроград эшчеләре, солдатлар, матрослар партиянең юлбашчысын зур рухлану белән каршы алалар. Ленин броневикка менә һәм Финляндия вокзалы янында ялкынлы речь сөйли. Бу речен ул „Яшәсен бөтен дөньяда социалистик революция!" дигән лозунг белән тәмам итә.

4 нче апрельдә Ленин сугыш һәм революция турында большевиклар җыелышында доклад ясый, аннары шул ук көнне докладының тезисларын большевиклар һәм меньшевиклар катнашы белән булган җыелышта кабатлый. Бу Лениннең атаклы Апрель тезислары иде.

Ленин үзенең докладын илдәге хәлгә характеристика бирүдән башлый. Ул, Вакытлы хөкүмәтнең империалистик характерын фаш итә, бу хөкүмәт капиталистик характерда булганлыктан сугышның һич шиксез империалистик талау сугышы булып калачагын күрсәтә.

Хәзер патша булмагач, оборончылык бик законлы нәрсә дип массаны алдаучы соглашатель партияләрнең, меньшевикларның һәм эсерларның хыянәтчелек политикасына Ленин җимергеч удар ясады һәм фаш итте. Ленин оборончылыкка аз гына ташлама да ясарга ярамаганлыкны, аның социализмга хыянәт итү һәм рус революциясенең алдагы хәрәкәтенең һәм уңышының иң явыз дошманы икәнлеген күрсәтеп үтте.

„Лениннең Апрель тезислары буржуаз-демократик революциядән социалистик революциягә күчү өчен, революциянең беренче этапыннан икенче этапына—социалистик революция этапына күчү өчен партиягә көрәшнең даһи планын бирде". (ВКП(б) тарихы, бит 209—210).

Большевиклар партиясе бу бөек тарихи бурычны тормышка ашыруга үзенең үткәндәге бөтен эше белән хәзерләнгән иде.

Ленин „Нәрсә ул „халык дуслары" һәм алар социал-демократларга каршы ничек сугышалар" дигән хезмәтендә, 1894 нче елны ук инде, буржуаз-демократик революциянең социалистик революциягә үсеп әверелүе турында язган иде. „Ике тактика" исемле китабында 1905 нче елны ул үзенең бу теориясен тагын да тирәнәйтте. Беренче империалистик сугыш елларында, Ленин, капитализмның тигезсез үсүе турындагы законны ачып, аерым алынган бер илдә социализмның җиңүе мөмкинлеге турындагы нәтиҗәгә килгәннән соң, бу теория тагын да баетылды.

Лениннең Апрель тезисларындагы **яңалык** шуннан гыйбарәт иде ки, бу тезислар социалистик революциягә күчүгә керешүнең теоретик яктан нигезләнгән **конкрет планын** бирделәр.

„Россиядә агымдагы моментның үзенчәлеге революциянең беренче этапыннан, пролетариатның җитәрлек аңлы һәм оешкан булмавы аркасында властьны буржуазиягә биргән беренче этапыннан,—аның властьны пролетариат һәм крестьяннәрнең ярлы катлаулары кулына бирергә тиешле булган **икенче** этапына **күчүдән** гыйбарәт". (Ленин, XX том, 88 нче бит).

Лениннең бу планы, беренчедән, илдәге барлык җирләргә национализация ясауны, илдәге барлык банкларны бер гомуми милли банкка кушуны һәм аңа эшче депутатлары Советы тарафыннан контроль кертүне, җәмагат производствосына һәм продуктларны бүлүгә контроль булдыруны үз эченә ала иде.

Икенчедән, бу план парламентар республикадан Советлар республикасына күчүне күздә тота иде.

Царизмга каршы коралы восстание органнары, революцион властьның башлангычлары сыйфатында Советлар 1905 нче елгы революция чорында ук барлыкка килделәр. Париж коммунасы һәм Россиядә булган революцияләрнең тәҗрибәләрен туплап, Ленин, пролетариат диктатурасының иң яхшы политик формасы—парламентар демократик республика түгел, бәлки Советлар республикасы дигән нәтиҗәгә килде.

В. И. Ленин Петроградның Финляндский вокзалында броневиктан речь сөйли. (1917 нче ел). Художник П. Васильев рәсме (В. И. Ленин Үзәк Музее).

Ленин үзенең тезисларында, Советлар—коммунадан башка дөньяда әле һич тә күрелмәгән һәм бердән-бер мөмкин булган хөкүмәт дип, Советлар—**яңа тип дәүләт** дип күрсәтте.

Ленин, дәүләтнең яңа формасын ачып, марксизмның искергән положениеләренең берсен **алыштырды**. Бу положение буенча парламентар демократик республика капитализмнан социализмга күчү чорында җәмгыятнең бердән-бер уңайлы политик оешма формасы дип санала иде.

Парламентар республика иске дәүләт машинасын ватмый, полиция, чиновниклар, армия саклана һәм шуның өчен дә парламентар республикадан монархиягә кайту бик җиңел нәрсә булып тора.

„Парламентар республика түгел,—эшче депутатлар Советыннан аңа кире кайту артка таба бер адым атлау булыр иде,—бәлки бөтен илдә, түбәннән югарыга кадәр, эшче, батрак һәм крестьян депутатлары Советлары республикасы". (Ленин, том XX, бит 88) булдыруны куйды.

Ленин марксизм хәрефенә ябышып калмады, бәлки аны алга хәрәкәт иттерде, аны яңа тәҗрибә белән баетты.

„Бөтен власть Советларга!" дигән лозунг революциянең бу этапында большевиклар партиясенең төп лозунгысы иде, чөнки ул соглашатель партияләрне изоляцияләүнең һәм пролетариат диктатурасы җиңүнең әһәмиятле шарты иде.

Шулай итеп, Ленин революциянең тыныч үсүе турында установка бирде. Вакытлы хөкүмәткә карата Ленин аны хәзер үк бәреп төшерүне таләп итмәде, бәлки „Вакытлы хөкүмәткә берниндн булышлык күрсәтмәскә" (Ленин) дигән лозунгны куйды һәм аның барлык вәгъдәләренең ялганлыгын фаш итүне таләп итте.

Тезисларның ахрында Ленин партиябезнең исмен үзгәртүне таләп итте һәм аны коммунистлар партиясе дип исемнәргә тәкъдим итте.

Ленин большевиклар партиясенең соңгы теләге коммунизм төзү булганлыктан, „социал-демократия" дигән исемнең „социал" дигән өлеше фәнни яктан дөрес түгеллекне күрсәтте.

Бу исемнең **„демократлар"** дигән өлеше дә фәнни яктан дөрес түгел. Чөнки демократия—дәүләт формаларының берсе, ә безнең теләк—дәүләтсез җәмгыят строе төзү.

Болардан тыш, социализмга хыянәт иткән һәм бу исемне таплаган, буяган Икенче Интернационал партияләре һәм рус меньшевиклары да үзләрен социал-демократлар дип атыйлар иде.

Лениннең шушы күрсәтмәләреннән чыгып, партиябезнең VII нче съезды большевиклар партиясенең исмен үзгәртте.

Ниһаять, Ленин үзенең тезисларында социал-шовинизмнан, оппортунизмнан азат булган яңа, Өченче Коммунистик Интернационал төзүне таләп итте. 1914 нче елгы беренче империалистик сугыш башлангач II нче Интернационал тулысынча җимерелде. Икенче Интернационал юлбашчылары социализмга хыянәт иттеләр һәм ачыктан-ачык „үзләренең" милли буржуазияләре ягына чыктылар. Икенче Интернационал бер-берсенә каршы сугышучы аерым социал-шовинистик партияләргә аерылды.

Яңа, эзлекле революцион халыкара оешма кирәк иде һәм ул Ленин инициативасы белән 1919 нчы елның мартында төзелде. Бу—халыкара революцион пролетариатның сугышчан штабы—Өченче Коммунистик Интернационал булды.

Лениннең Апрель тезисларын меньшевиклар ачу белән каршы алдылар. Плеханов Лениннең бу тезисларын „саташу речe" дип атады. Меньшевик Чхеидзе „Революциядән читтә Ленин бер үзе генә калыр, ә без үз юлыбыз белән барырбыз" дип Ленинне куркытырга маташты.

Иудушка Троцкий, Ленин тезисларына каршы чыгып, большевизмга каршы булган „патшасыз, ә эшчеләр хөкүмәте" дигән лозунгны,—пролетариатның крестьяннәр белән союзына каршы юнәлдерелгән лозунгны яклады.

Лениннең Апрель тезисларын меньшевиклар һәм эсерлар гына түгел, бәлки партия эчендәге зур булмаган группа да дошманлык белән каршы алды.

Хыянәтчеләр, ике йөзлеләр—Каменев, Рыков, Бухарин, Пятаков һәм башкалар партиягә Лениннең социалистик революция планы белән коралланырга комачауларга маташтылар. Большевикларның Петроград һәм аннан соң апрель конференциясе Лениннең тезисларын тулысы белән кабул итте. Оппортунистлар фаш ителделәр.

Лениннең Апрель тезислары большевиклар партиясе хәрәкәтенең сугышчан программасы, социалистик революцияне тормышка ашыруның даһи планы булды. Ленин—Сталин партиясе, бу план белән коралланып, эшчеләрне һәм крестьяннәрне Бөек Октябрь Социалистик революциясенең җиңүенә алып килде.

Н. Ганиев.

ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторы.

ЛЕНА ВАКЫЙГАЛӘРЕ

1905—1907 нче еллардагы Россиядә беренче буржуаз-демократик революциядән соң канлы реакция еллары башланды. 1907 нче елның 3 нче июненә каршы төндә самодержавие тарафыннан икенче дәүләт Думасы таратылды. Думаның социал-демократлар фракциясе кулга алынды һәм алар патша судының карары белән каторгаларга, гомерлеккә сөргеннәргә җибәрелделәр. 1907 нче елның 3 нче июнендә өченче дәүләт Думасына сайлаулар турында самодержавие тарафыннан алдан ук хәзерләп куелган закон чыгарылды. Бу закон кара груһчы алпавытлар белән промышленность һәм сәүдә буржуазиясенең югары катлаулары арасындагы политик блокны ныгытты.

Столыпин реакциясе елларында төрмәләр, крепость һәм сөрген урыннары революционерлар белән тутырылдылар.

Эшчеләрнең матбугатлары һәм күпчелек профсоюз оешмалары таратылды. Эшчеләрне репрессияләү һәм җәзалауда самодержавиегә фабрика һәм завод хуҗалары да актив булышлык иттеләр. Алар эшчеләрне эшләреннән чыгардылар, „Кара кнәгәләр" кулланып анда забастовкаларга катнашкан эшчеләрне терки бардылар. „Кара исемлеккә" эләккән эшчеләр эшкә алынмадылар. Эшчеләрнең хезмәт хаклары 10—15 процентка кимеде, эш көне бөтен җирдә дә 10—12 сәгатькә кадәр озайтылды.

Канлы патша һәм асучы министр Столыпин хөкүмәте бигрәк тә эшчеләр сыйнфы партиясенә—большевиклар партиясенә каршы ерткычларча ташланды һәм бөтен көче белән эшчеләр сыйнфының партиясен тар-мар итәргә, аның җитәкчеләрен төрмәләргә утыртырга, сөргеннәргә җибәрергә керешде.

Ләкин хезмәт ияләре беренче чиратта пролетариат һәм аның җитәкчесе большевиклар партиясе патша самодержавиесенең мондый ерткычлыклары һәм коточкыч җәберләүләре белән килешеп кала алмады. Большевиклар партиясе җитәкчелегендә үзләренең иң явыз дошманнары булган самодержавиегә, эксплоататорларга каршы көрәшкә яңадан күтәрелә башладылар.

Столыпин реакциясенең тантанасы озак гомерле була алмады. 1910 нчы елда инде Россиянең күп кенә урыннарында эшчеләрнең стачкалары булды. 1911 нче елда исә стачкаларга катнашучыларның саны йөз меңнән артты.

Ленин һәм Сталин бу стачкаларда пролетариатның үзенең дошманнарына каршы яңа һөҗүмгә килүләрен күрделәр. Моны большевикларның 1912 нче елның январенда булган Прага конференциясе дә шулай билгеләде һәм эшчеләр хәрәкәтенә җитәкчелек итү өчен конкрет күрсәтмәләр кабул итте.

Ликвидаторлар һәм троцкичылар революцияне күмәргә никадәр генә маташсалар да, революция үлмәде, эшчеләр хәрәкәте яңадан күтәрелде.

Ленин һәм Сталин революцион хәрәкәтнең чын күтәрелешен Лена эшчеләрен ату белән башланган массовый политик стачкалардан хисапладылар. „Лена эшчеләрен ату массаның революцион настроениесенең массаның революцион күтәрелешенә күчүенә сәбәп булды" (Ленин).

***

Революциягә кадәрге Россиянең ерак бер почмагында—Иркутский тимер юлы станциясеннән 1.700 чакрым ераклыкта, Себер тайгасының 40 мең гектар чамасы җирендә 423 Лена алтын приискалары урнашкан. Бу приискаларга 1861 нче елдан башлап, 1910 нчы елга кадәр рус алпавытлары һәм капиталистлары хуҗалык иттеләр. 1910 нчы еллардан башлап бу приискаларның күпчелек өлеше Англия капиталистлары кулына күчте.

Лена приискасындагы эшчеләр гадәттән тыш авыр шартларда эшләделәр. Көнгә 11—12 сәгать эшләгән эшчеләргә эштән кайткач ял итәргә дә мөмкинлек юк иде. Эшчеләр караңгы, юеш баракларда өчәр катлы сәндерәләрдә йоклыйлар, эшләгән вакытта өстән су агып торган алтын шахталарында, юешләнеп кайткан киемнәрен дә шунда ук киптерәләр иде.

Приискадагы 6 мең эшчегә 500 дән артык хезмәткәр һәм карап йөрүчеләр була. Ә эшчеләрне дәвалау буенча бөтен приискалардагы эшчеләргә бары тик бер генә врач хезмәт күрсәтә. Ул да эшчеләрнең авырткан тешләрен алу өчен дә 2—3 сум акча алып кына эшли. Эшчеләрнең эшләгән хезмәт хакларының бик аз өлеше генә кулларына бирелә. Калган өлеше начар сыйфатлы продукт белән түләнә. Прииска хуҗалары эшчеләргә бирә торган бу продуктларның бәяләрен Россиянең үзәк шәһәрләренә караганда берничә тапкыр югары бәя белән саталар.

Приискаларның администрацияләре полиция һәм жандарм ярдәме белән үзләренең хуҗалары Англия капиталистларына һәм аларның рус компанионнарына ярау өчен эшчеләрне ничек теләсәләр шулай изделәр һәм мәсхәрәләделәр.

Лена эшчеләре прииска хуҗаларының кабахәт рәвештә эксплоатацияләүләренә каршы стачка, забастовкалар оештыру белән җавап бирделәр. 1912 нче елның 28 нче февралендә Андреевка приискасындагы эшчеләр забастовка башладылар. Бу забастовкага хатын-кыз һәм яшь үсмер балалардан башка 6.258 эшче катнаша. Барлык приискалардан, прииска идарәсе белән сөйләшү өчен выборныйлар сайлыйлар. Бу выборныйлардан башында Үзәк Бюро торган хәлдә стачка комитетлары төзелә. Стачка комитеты большевиклар җитәкчелегендә эш итә. Эшчеләр үз выборныйлары алдына 22 пункттан торган таләпләрен куялар һәм бу таләпләрне прииска идарәсенә тапшыруны йөклиләр. Эшчеләрнең бу таләпләренә: хезмәт хакын тулысы белән вактында түләү, торак урыннарын тәртипкә салу, эшчеләргә 8 сәгатьлек эш көне булдыру, штрафларны бетерү, хезмәт хакын 20 процентка арттыру һәм башка шундый экономик таләпләр кергән иде.

Прииска хуҗалары эшчеләрнең бу таләпләрен хәтта тыңларга да теләмәделәр. Киресенчә, стачкага катнашучы эшчеләрне эзәрлекләү, продуктлар бирмәү, квартираларыннан урамнарга чыгарып ташлау, конвой белән эшчеләрне икенче урыннарга җибәрү кебек кискен чаралар куллана башладылар.

Прииска хуҗаларының болай котырынып эшчеләр өстенә ташланулары эшчеләрнең аларга каршылык күрсәтү хәрәкәтен бастыра алмады. Прииска хуҗалары бу чаралар белән эшчеләр хәрәкәтен бастыра алмагач, жандарм ротмейстеры Трещенков карамагына бер рота солдат чакырдылар. Патша министре Макаров белән сөйләшеп стачка комитетын һәм барлык выборныйларны кулга алдылар. Бу да стачкачыларның ирекен җимерә алмады. Забастовка дәвам итте, эшчеләр үзләре сайлаган выборный иптәшләрен тоткынлыктан азат итү өчен көрәштеләр.

17 нче апрельдә иртә белән эшчеләр үзләренең җыелышларында таләпләренә ирешкәнчегә кадәр забастовканы дәвам иттерәчәкләрен белдерделәр һәм җыелыштан соң 3 меңле коралсыз эшчеләр массасы прииска администрациясенә, җирле властька кулга алынган иптәшләрен азат итүне сорарга юнәлделәр. Тар сукмаклардан баручы эшчеләр Надеждинский приискасына җиткәч, башында Трещенков торган бер рота солдатның стройга тезелеп торганын күрделәр. Шунда булучы бер прииска инженеры Трещенковка солдатларның эшчеләргә атмавын сорады һәм эшчеләрне таралырга өндәде. Алдан килүче эшчеләр туктадылар. Арттагылары исә алда нәрсә булганны күрү өчен алга омтылдылар. Шул вакытта Трещенков коралсыз эшчеләр толпасына залп белән атарга команда бирә. Нәтиҗәдә 500 дән артык эшче үтерелә һәм яралана.

Лена эшчеләрен ату бөтен ил пролетариатын дулкынландырды. Петроград, Москва, Рига һәм Россиянең башка шәһәрләрендәге эшчеләр Лена эшчеләрен атуга җавап итеп самодержавиегә каршы массовый забастовкалар, демонстрацияләр һәм митинглар оештырдылар.

Лена эшчеләрен ату уңае белән иптәш Сталин „Звезда" газетасына болай дип язды: „Ленадагы атулар дәшми тору бозын ваттылар, һәм—халык хәрәкәте елгасы кузгалды. Кузгалды!.."

Ленадагы атулар Бөтенроссия күләмендә революцион хәрәкәтне тагын да җәелдерде. Лена вакыйгаләре чорында забастовкаларга катнашучы эшчеләрнең саны 300 мең, май аена 400 мең, ә бөтен 1912 нче ел буена миллионнан артык эшчеләр революцион хәрәкәткә катнаштылар. 1912 нче елгы стачкалар политик төс алды һәм: демократик республика, сигез сәгатьлек эш көне, алпавытлардан барлык җирләрне конфискацияләү, дигән большевистик лозунглар астында барды. Ил яңа революцион күтәрелеш полосасына керде.

Ленин—Сталин җитәкчелегендә большевиклар партиясе меньшевикларга, эсерларга һәм эшчеләр сыйнфының башка барлык дошманнарына каршы көрәштә эшчеләр массасын үз тирәсенә туплап, аларны 1917 нче елның октябрендә җиңүле социалистик революциягә алып килде.

„Үтелгән юлга карап, союзның эшчеләре: Бодайбо эшчеләренең бер генә тамчы каны да бушка югалмады, чөнки пролетариатның дошманнары тиешле җәзаларны алдылар, ә пролетариат инде аларны җиңүенә ирешете дип әйтә алалар" (Ленин—Сталин Лена вакыйгаләре турында. Бит 54).

Социалистик илебезнең халыклары бөек эшләр өчен корбан булган үз туганнарын онытмыйлар һәм онытмаслар.

Г. Исламов.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

Тракторлар белән чәчү башланды

АКТАНЫШ, 16 апрель. (Телефон буенча). Бүген районның барлык колхозлары да иртә культураларны чәчү эшенә чыктылар. Ленин исемендәге колхозда 140 гектар бодай чәчелде инде. Шуның 85 гектары тракторлар көче белән чәчелде. Кичә бу колхозда 2 трактор 21 әр гектар чәчеп, норманы арттырып үтәделәр.

„Электро", „Үрнәк" һәм „Кызыл Көч" колхозларында да тракторлар белән чәчү эшләре башланды. Чәчүне агротехника кагыйдәләренә төгәл туры китереп үткәрү, яхшы сыйфатлы итеп эшләүгә күзәтчелек итү һәм колхозларга, бригадаларга ярдәм күрсәтү буенча районның барлык агрономнары колхозларда эшлиләр.

Бәшәрев.
Район җир бүлеге мөдире.

МӨСЛИМ, 16 апрель. (Телефон буенча). 14 нче апрельгә районда барлыгы 1.931 гектар иртә культуралар чәчелде. „Лена" колхозы 222 гектар, „Новая путь" колхозы 172 гектар, „Кызыл Октябрь" колхозы 117 гектар бодай, борчак һәм солы культуралары чәчтеләр инде.

Районда 68 колхозның 62 сендә чәчү эшләре массовый төстә бара.

Исмагыйлев.

ТРАКТОРЧЫЛАР ЯРЫШЫП ЭШЛИЛӘР

Әлмәт МТС ы трактор бригадаларының күпчелеге язгы сөрү эшенә керештеләр. Бригадалар һәм тракторчылар арасында Беренче Май алды ярышы көннән-көн җәелә. „Морат" колхозында эшләүче трактор бригадасы (бригадиры иптәш Газизов) 70 гектар сөрде инде. Тракторчы Садыйков һәм Брагин иптәшләр үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә беренче көнне үк 11 гектар урнына 15 гектар сөрделәр. „Зәй" колхозында эшләүче бригада (бригадиры иптәш Хәйреттинев) бигрәк тә яхшы күрсәткечләр бирде. Бу бригадада беренче көнне үк тракторчыларның бөтенесе дә норманы арттырып үтәделәр. Миңнури иптәш Кәримова норманы 170 процент, Кәримев һәм Юсупов иптәшләр 200 процент итеп үтәделәр.

Ләкин районның кайбер колхозларында трактор бригадаларының бөтенләй хәзерлексез каршы алынуларын әйтергә кирәк. Шул ук „Зәй" колхозында (председателе иптәш Гәрәев) трактор бригадаларының торак вагоннарына ремонт ясалмаган, тракторчылар өчен кырда җәмагат туклануы оештырылмаган.

„Ярыш", „Ильком" һәм „Октябрь" колхозларында да шундый ук хәл. „Марс № 1" колхозында (председателе иптәш Шәймиев) тракторларга ягулык ташу өчен иң начар атларны беркеткәннәр. Ягу материалларын кырга вактында китереп җиткермәү сәбәпле 14 нче апрельдә бу колхозда ике трактор тоташтан 14 сәгать эшсез торды.

З. Салахеттинов.

Нормаларны арттырып үтиләр

ПУЧЫ, 16 апрель. (Телефон буенча). Районда 600 гектар мәйданда иртә культуралар чәчелде. Күҗәкә авылы, Сталин исемендәге колхоз 100 гектар, „Ирек" колхозы 85 гектар солы һәм бодай чәчтеләр инде. Чәчүдә сыйфат ягына нык әһәмият бирелә. „Мәсгут" колхозында чәчелгән 3 гектар солының 10 процентын күмдерми калдыру факты беленгән иде. Бу җитешсезлек шунда ук төзәтелде.

„Правда" колхозында кыр эшләре аеруча оешкан рәвештә бара. Колхозчылар нормаларны арттырып үтиләр. Шәвәлиев һәм Нәбиева иптәшләр 5 гектар культивацияләү нормасын системалы рәвештә 6 гектар итеп үтиләр. Тырмалауда 5 гектар норманы иптәш Маликова 6,5 гектар итеп, Куматов һәм Ганеев иптәшләр 7 шәр гектар итеп үтиләр. Шулай ук Галиуллин һәм Әюпов иптәшләр дә көнгә бер гектар урнына 1,25—1,30 гектар сөрәләр. Эшнең сыйфаты яхшы.

Герасимов.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә. Рәсемдә: Грузия ССР павильоны работнигы иптәш Е. М. Митрошкин Оранжереядә кышлаган лимон агачларының бөгелгән ботакларын бәйли.

С. Шагаль фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ИГТИБАРСЫЗЛЫК

Балтач МТС ында 1938 нче елны тракторчы хатын-кызлардан аерым бригада төзелгән иде һәм бригада шул елны яхшы гына эшләде дә. Ләкин МТС җитәкчеләре тарафыннан тиешле игтибар булмаганлыктан, бригада үткән елны таралды. Бу МТС та тракторчы хатын-кызларга эш шартлары булдыруга бөтенләй әһәмият бирелми. Кайбер иптәшләрнең (Гумерова, Фатыйхова һ. б.) быел МТС ка эшкә килмәүләрен тик шуның белән генә анлатырга мөмкин. Быел тракторчылар хәзерләү курсын бетереп чыккан 23 хатын-кызның 8 зенә бүгенге көндә дә әле тракторлар беркетелмәгән.

Р. Тимиров.

АЛДЫНГЫЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ ӨЧЕН

Кама Тамагы МТС ы хезмәт күрсәтә торган колхозларда быел 36 трактор эшләячәк. Шулардан 8 бригада оештырылды. Бригадаларның 6 сы үзләре эшләячәк колхозларга киттеләр инде.

Бригадалар һәм тракторчылар арасында социалистик ярыш договорлары төзелде. Бригадир иптәш Прохоров бригадасындагы һәрбер СТЗ-НАТИ тракторы белән 1.600 гектар, һәрбер СТЗ тракторы белән 750 гектар эшләргә йөкләмә алды. Тракторчылардан иптәш Молов СТЗ-НАТИ тракторында үз сменасында 900 гектар, иптәш Совожеев 950 гектар эшләргә йөкләмә алдылар.

Социалистик ярышта өстен чыккан бригаданы бүләкләү өчен МТС дирекциясе кызыл байрак хәзерләде. Байрак белән бергә 500 сум акча да биреләчәк.

Нәҗметтинев.

Ягулык һәм майлау материалларын җитәрлек хәзерләргә!

Колхоз, совхоз кырларында кызу эш башланды. Тракторларның тоткарсыз эшләүләре, барыннан элек, аларны ягулык һәм майлау материаллары белән җитәрлек тәэмин итүгә бәйләнгән. Үткән ел ягулык һәм майлау материаллары белән вактында тәэмин ителмәү аркасында Рождественский, Тархан, Биләр, Чиябаш МТС лары кебек байтак МТС ларда тракторларның туктап тору фактлары күп булды. Шунлыктан, бу МТС ларда үткән ел тракторлар белән эшләү планының үтәлми калуы очраклы хәл түгел. Ни өчендер, МТС директорлары бу ачы сабакларны быел онытканнар.

Тархан МТС ында (директоры иптәш Насыйбуллин) 90 тонна урнына бары 37 тонна, Биләр МТС ында (директоры иптәш Кадыйров) 135 тонна урнына 48 тонна, Чиябаш МТС ында (директоры иптәш Галимов) 95 тонна урнына 36 тонна, Ромадан МТС ында 95 тонна урнына 42 тонна гына ягулык һәм майлау материаллары китерелгән.

Газогенераторлы тракторлар өчен ягулык хәзерләү тагын да начаррак тора. Кукмара МТС ында 2.100 кубометр ягулык хәзерләнергә тиеш. Әле бары 300 кубометр утын хәзерләнгән һәм шуның бер генә кубометры да шакмакка туралмаган. Бу МТС ның җитәкчеләре газогенераторлы 12 тракторны ничек эшләтергә уйлый торганнардыр?

Рождественский МТС ында газогенераторлы тракторлар өчен хәзерләнгән 400 кубометр утынны башка урыннарга тотып әрәм-шәрәм иткәннәр.

МТС та газогенераторлы 6 тракторга ягулык кирәк булуы директор иптәш Галиуллинның хәзер генә исенә төшкән. Анда да әле, ягулыкны урында хәзерләү өчен ашыгыч чаралар күрәсе урнына, үзенең вәкилен... Казанга әзер шакмак утын эзләргә җибәрә. Ләкин Казанда Галиуллин өчен бер кем дә ягулык хәзерләп куймаган, әлбәттә.

Рождественскийда тракторларга ремонт ясау эше дә 10 нчы апрельгә 62,3 процентан артмый. Бу тривогалы хәл Татнаркомзем работникларын да борчымый. Хәлне урынга барып тикшерү, кискен чаралар күрәсе урнында, алар йомыш төшкәндә, маглүматлар кирәк булганда кабинеттан телефон шалтырату, бер-бер артлы кәгазьләр, телеграммалар җибәрүдән башка бу МТС ка карата бер нәрсә дә эшләгәннәре юк.

Газогенераторлы тракторлар өчен ягулык хәзерләү эшләре Черемухово, Морт МТС ларында да бик начар тора. Эшнең шундый хәлдә булуы тракторлар паркын ягулык материаллары белән тулысынча тәэмин итү өчен кискен чаралар күрүне таләп итә. Бу МТС ларның директорлары һич кичекмәстән сыек ягулык материаллары ташуны һәм газогенераторлы тракторлар өчен шакмак утын хәзерләү, шакмакларны сушилкаларда киптерү эшләрен оештыруда бик ашыгыч чаралар күрергә тиешләр.

Ягулык һәм майлау материалларын экономияле тоту да гаят җаваплы эш. Үткән ел бу тармакта Актаныш, Мөслим МТС лары һ. б. бик яхшы үрнәк күрсәттеләр. Актаныш МТС ында 72,4 тонна, Мөслим МТС ында 72,2 тонна ягулык-майлау материалларына экономия ясалды. Шул ук вакытта Рождественский МТС ында 32,1 тонна, Зөя МТС ында 36,8 тонна, Тат. Ходяш МТС ында 43,4 тонна ягулык һәм майлау материалларын нормадан артык тоттылар. Быел бер генә МТС директоры да, бригадир да, бер генә тракторчы да мона юл куймаска, бер генә килограмм ягулыкны да әрәм итмәскә, артык тотмаска тиеш.

КОЛХОЗ СТРОЕН ТАГЫН ДА НЫГЫТУ ӨЧЕН

КАЙБЫЧ, 16 апрель. (Телефон буенча). „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр" турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын Кайбыч районы колхозларында зур күтәренкелек белән каршыладылар. Карарны өйрәнүдә һәм карар нигезендә практик чаралар билгеләүдә булышлык күрсәтү өчен партия һәм совет активыннан колхозларга кешеләр җибәрелде.

Камиль Якуб исемендәге колхоз членнарының шушы уңай белән үткәрелгән җыелышы колхозда кошчылык фермасы оештыру турында карар кабул итте. Хәзер колхоз правлениесе бу ферманы оештыру өчен хәзерлек эшләренә кереште.

Карл Маркс исемендәге колхозда үткәрелгән җыелышта чыгып сөйләүче колхозчы иптәш Зиннәтуллин: „Бу карар колхоз строен тагын да ныгыту өчен, колхозчылар тормышын тагын да яхшырту өчен чыгарылган. Аны тулысынча тормышка ашыру өчен көрәшү—безнең изге бурычыбыз булып тора" диде.

Фирушин.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ ИКЕНЧЕ СЕССИЯСЕ

15 нче апрельдә Казан Шәһәр Советының икенче сессиясе булды. Сессия Казан шәһәрендәге башлангыч мәктәпләрдә, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә уку-укыту һәм тәрбия эшләренең торышы турындагы мәсьәләне тикшерде. Шулай ук шәһәр советы башкарма комитеты аппараты буенча кайбер оештыру чараларын хәл итте.

Сессиянең көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча ГорОНО мөдире, депутат Бикшанский доклад ясады. Соңгы биш ел эчендә шәһәрдә башлангыч, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләр саны 101 гә җиткән һәм аларда 60 меңнән артык бала укый. Урта мәктәпләр саны соңгы биш ел эчендә ике тапкыр үскән. 1934 нче елны Казанда 20 урта мәктәп булган булса, хәзер алар 40 исәпләнәләр. Шәһәрдә уку яшендә булган балаларны мәктәпләргә тарту буенча һәм аларга яхшы уку өчен шартлар тудыру буенча зур гына эшләр эшләнгән. Җәмагат оешмалары һәм укучыларның ата-аналары белән мәктәпләр арасындагы элемтә туктаусыз ныгый бара һ. б.

Шуның белән бергә, мәктәпләрнең эшләрендә зур гына җитешсезлекләр дә яшәп килә әле. Бу җитешсезлек уку-укыту эшләренең сыйфатында, укучыларның өлгерешләрендә аеруча күзгә бәрелә. Хәзерге көндә Казан шәһәрендәге башлангыч мәктәпләрдә, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә укучылар арасында дәресләрдән өлгермәүче 14.214 бала бар. Бу—барлык укучыларның 10,7 проценты дигән сүз.

Шул ук вакытта укучы балаларның мәктәптән китүләре дә шактый урын алган. 1939—1940 нчы уку елының үткән айлары эчендә шәһәр мәктәпләрендә укучылар арасыннан 718 бала һичбер сәбәпсез мәктәпләрдән киткәннәр. Кайбер мәктәпләрдә дисциплинасызлык күренешләре һаман да дәвам итә. Менә болар барсы да укучылар арасында тәрбия эшләренең һәм масса-аңлату эшләренең канәгатьләнерлек булмавы турында, РОНО һәм ГорОНО җитәкчеләре тарафыннан аерым мәктәпләргә булышлыкның җитәрлек булмавы турында сөйлиләр.

Доклад буенча чыгып сөйләүче депутатлар шәһәр мәктәпләрендә яшәп килә торган җитешсезлекләрне һәм аларны тудыручы җитәкчеләрне каты тәнкыйть иттеләр һәм бу җитешсезлекләрне бетерү буенча практик тәкъдимнәр ясадылар. Мәктәптәге тәрбия белән мәктәптән тыш тәрбия эшләре арасында ныклы бәйләнеш булмавын, аларның планлы тәртиптә алып барылмауларын депутатлар конкрет фактлар белән күрсәттеләр. Пионерлар клубына, яшь тамашачылар театрына, пионер кино-театрына игтибарның җитәрлек булмавы, балалар парклары оештыру буенча практик чаралар күрелмәү турында аеруча күрсәтелеп үтелде. Депутатлар башкарма комитетның игтибарын укучы балаларның җәйге ялларын яхшы итеп оештырырга һәм алдагы уку елына хәзердән үк хәзерләнә башларга кирәклеккә юнәлдерделәр. Беренче мәсьәлә буенча барлыгы 11 иптәш чыгып сөйләде.

Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча фикер алышулар тәмам булганнан соң, Сессия Казан шәһәрендәге башлангыч мәктәпләрдә, урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә уку-укыту эшләрен һәм укучылар арасында коммунистик тәрбия эшләрен яхшырту буенча практик чаралар билгеләп, карар кабул итте.

Оештыру мәсьәләләре буенча Сессия Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитетының гомуми бүлегенә һәм җирле промышленность бүлегенә мөдирләр билгеләү эшен карады. Башкарма комитетның гомуми бүлеге мөдире итеп Нечаев, җирле промышленность бүлеге мөдире итеп Исламов иптәшләр расландылар. Шуның белән Казан Шәһәр Советының икенче сессиясе тәмам булды.

1 НЧЕ МАЙГА ХӘЗЕРЛЕК

ШӘҺӘР УРАМНАРЫН БИЗӘҮ

Халыкара пролетариат бәйрәме булган Беренче Майга карата Казан шәһәренең урамнарын һәм мәйданнарын бизәүгә хәзерлек бара.

Бауман, Чернышевский, Карл Маркс урамнарын, Ирек һәм Куйбышев мәйданнарын бизәүгә аеруча әһәмият бирелә. Ирек Мәйданында Кызыл Армия йорты оборона темасына, Язу машиналары заводы „Сталинчыл өченче бишьеллыкта промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының үсеше" дигән темага, Юридик институт бинасы Сталин Конституциясе темасына бизәлә.

Бауман урамында Матбугат йортына Политбюро членнарының зур портретлары, шулай ук СССР геройларының һәм атаклы кешеләрнең рәсемнәре куела. Зур театрның бизәлүе зур Волга проблемасына багышлана. Куйбышев мәйданы „СССР халыкларының дуслыгы" дигән темага, Карл Маркс урамы культура төзелешенә карата, В. И. Ленин исемендәге Казан Дәүләт университеты бинасы „СССР да белем алуга хокук" дигән темага бизәләләр. Вокзал янындагы мәйдан СССР да тимер юлларының үсешен чагылдыра торган плакатлар һәм рәсемнәр белән бизәләчәк.

БӘЙРӘМ ХӨРМӘТЕНӘ

Казанның 2 нче тегү фабрикасы коллективы Беренче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршылауга хәзерләнә. Фабрика беренче кварталның производство планын 116 процент итеп үтәде. 2 нче цехта иптәш Захарова агрегаты, 4 нче цехта Шәһидуллина һәм Гаврилова иптәшләрнең агрегатлары апрель аенда көнлек нормаларны системалы рәвештә арттырып үтәп киләләр.

Фабрикада эшләүче хатын-кызлар оборона эшләре белән бик нык кызыксыналар. Шушы көннәрдә 34 кеше „ПВХО" значогына нормалар тапшырды. 30 кеше 1 нче Майга „Ворошиловча атучы" значогына норма тапшыруга хәзерләнә. Хатын-кызлардан значкистлар хәзерләү өчен яңа өч түгәрәк төзелде. Беренче Май демонстрациясе вактында 2 нче тегү фабрикасы коллективының колоннасы оборонага багышланып оештырылачак.

Фабриканың эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен 29 нчы апрельдә Пионерлар йортында Беренче Майны каршылауга багышланган тантаналы җыелыш үткәрелә. Халыкара пролетариат бәйрәме турында докладтан соң кино-сеанс биреләчәк һәм үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләренең чыгышлары булачак.

ДЕПУТАТЛЫК БУРЫЧЫН ҮТӘГӘНДӘ

Бездә әле тиз генә борыла алмый торган бюрократлар юк түгел. Мондый кешеләрне совет, җәмагат оешмаларында да очратырга була әле. Шулай ук бер әйтү белән генә аңламый торган мондый „каты колаклы" егетләрнең кайберләре коммуналь хуҗалык эшләрен дә башкарып утыралар. Шәһәребезнең Киров исемендәге урамында 163 нче номерлы домуправлениедә менә шушындый типларның берсе эшли. Бу, Денисов фамилияле берәү. Ул үзе эшли торган домуправление карамагындагы йортларның төзеклеген, чисталыгын кайгырта торган кеше түгел. Ишек аллары да, бәдрәфләре дә һәр вакыт шакшы аның.

Март ахырларында крестьян йорты менә шушы кешенең бәласенә юлка, икенче төрле итеп әйткәндә 62 нче номерлы йортның ишек алды тазартылмавы аркасында крестьян йорты үз карамагындагы ашханәне берничә көнгә ябарга мәҗбүр була. Әлеге Денисовка бер әйтәләр, ике әйтәләр, ләкин бер нинди дә нәтиҗә чыкмый.

Шуннан соң крестьян йортының администрациясе Казан шәһәренең Сталин райсоветы депутаты Рәхим иптәш Замановка мөраҗәгать итә. Депутат Заманов үзенең өстенә йөкләнгән бөек бурычны, дәүләт эшен үтәргә тотына, бик тиз райсовет белән баглана һәм санитарный инспектор иптәш Овчинников килеп җитә.

Икенче көнне инде 62 нче номерлы йорт ишек алдындагы пычраклар да тазартыла һәм әлеге Денисовка карата да тиешле чара күрелә.

Шушы гади генә бер конкрет эш йөзендә меңнәрчә сайлаучылар депутат Замановның үзләренеке икәнлеген, сайлаучылар күшканча тиз һәм нәтиҗә белән эшләүче депутат икәнлеген күрәләр.

Ул райсоветның сәламәтлек саклау комиссиясенә беркетелгән. Шунлыктан бу көннәрдә аның эше аерата күп. Чөнки тышта яз. Ә яз ул кыш көне күзгә күренмәгән күп кенә чүпләрне чыгарганнан-чыгара бара. Депутат Замановны бер караганда ишек алдында, икенче караганда базар мәйданында, өченче караганда кибетләрдә күрәсең. Үзен-үзе тотуы белән гаҗәп гади Рәхим Заманов бик зур эшләр башкара. Ул бер нәрсәне дә вак эш дип карамый, чөнки зур эшләрнең „вак" эшләрдән башланганын ул яхшы аңлый. Әгәр дә базар мәйданындагы махсус урыннарда май сатучыларның җиңсәләре юк икән, яки ит белән сәүдә итүчеләр өсләренә халат кимәгәннәр икән, яки үлчәүләр шапшак икән, ул боларга карап тыныч кына кала алмый. Шунда ук базар комитеты алдына үзенең тәкъдимнәрен куя. Башка депутатлар белән бергәләп, алар конкрет чаралар үткәрергә билгелиләр:

— Базар мәйданында һәр вакыт кайнаган су булсын.

— Ит лабазлары бик тиз яңадан буятылсын.

— Сөт сату урыннары ябылулы булсын.

Депутатның авторитеты зур. Аны тыңлыйлар, чөнки депутат тәкъдимнәре—ул, власть вәкиленең тәкъдимнәре!

Ул соңгы көннәрдә махсус комиссиянең катнашы белән, бигрәк тә, санитария - гигиена кагыйдәләрен колхоз базары комитетының ничек үтәвен тикшерү белән шөгыльләнә. Базар комитеты шушы тикшерүләрдә ачылган җитешсезлекләрне ничек бетерүе турында апрель ахрында Сталин райсоветының сәламәтлек саклау комиссиясендә доклад ясаячак. Депутатларның тәкъдимнәре тормышка ничек ашырылганлыгы менә шушы утырышта кабат тикшереләчәк.

Депутат Замановның үти торган эшләре, әлбәттә, болар гына түгел. Аңа еш кына бу яки теге мәсьәлә буенча күпләр мөраҗәгать итәләр. Әйтик, магазиннарда, икмәк кибетләрендә товарны ким үлчәп, потребительләрне алдау фактлары сизелә. Заманов бу фактларны шунда ук тикшереп, чарасын күрә. Яки икенче бер факт—крестьян йортының ашханәсендә кайбер официанткалар касса белән алдан сүз куешып, бер үк талонны берничә тапкыр саталар. Депутат Заманов үзе эшли торган оешмада булган бу алдашулар турындагы беренче сигнал белән үк аны бетерү чарасына керешә. Ул мондый урлашуларга каршы җәмагать фикерен туплый, крестьян йортының активы белән берлектә хәрәкәт итә. Һәм нәтиҗәдә һәрбер сатылган талонны, шуның буенча аш җибәргәннән соң, суыргычланган махсус ящиккә салу тәртибе кертелә. Ашханәнең үзеннән, бухгалтериядән һәм җәмагать оешмалары вәкилләреннән төзелгән комиссия көн саен шушы ящикне ачып, сатылган талоннар белән кухнядан җибәрелгән аш санын тикшереп тора. Урлашырга һич кенә дә юл куймый торган бу гади тәртипне кертүгә сәбәпче кем?—Депутат Заманов. Дөрестән дә, кайбер мәсьәләләрдә административ чаралар гына җитми, ә менә шулай җәмагатчелек белән бергә хәрәкәт итү зур файда бирә бит!

Депутат Заманов үзенең эше турында күп сөйләргә яратмый. Ләкин халык, аны депутат итеп сайлаган халык, аның эше турында рәхәтләнеп сөйли:

— Эшне каян тотып башларга белә, тормыш тәҗрибәсе бар, халык өчен файдалы ул,—диләр аның сайлаучылары. Ул, чынлап та, халык белән бик тыгыз бәйләнештә эшли һәм алар өчен хезмәт итә.

Әгәр дә крестьян йорты ашханәсенә барып керсәгез, сезне анда какча гына гәүдәле, бик җиңел сөякле, 55 яшьләр чамасында, күзлекле бер өлкән генә швейцар каршылар. Ул биредә тоташтан 17 ел инде швейцар булып эшли. Шушы швейцарны сез еш кына райсоветта, базар мәйданнарында дәүләт өчен әһәмиятле мәсьәләләр хәл итеп йөргәнен күрерсез.

Аның көне иртәдән кичкә кадәр эш белән тулы. Ул үзенең швейцарлык хезмәтен үтәү белән бергә, депутатлык бурычын да үти. Эш сәгате тәмам булгач та, крестьян йортының дворларын әйләнеп чыга, андагы тәртипне, чисталыкны тикшерә, ә кичләрен ул күбесенчә читальняда була. Монда ул үзенең белемен арттыру өстендә эшли. Аның иң кызыксына торган мәсьәләсе—ул, халыкара хәлләр. Ул бу мәсьәләдә шактый тирән керә. Хәер, бигрәк тә халык вәкиле өчен, депутат өчен башкача булу мөмкин дә түгел бит.

Гади бер кеше үз өстенә төшкән депутатлык бурычларын менә шулай үти.

Г. Галиев.

Уйлап табучылар

Киров исемендәге 4 нче ясалма каучук заводының сигезенче цехындагы яшь уйлап табучылар коллективы орденлы Татарстанның XX еллыгы хөрмәтенә уйлап табучылык эшендә актив катнашырга йөкләмә алганнар иде.

Күп станокта эшләүче стахановчылар, инженер-техниклар һәм механиклар инде күп кенә кыйммәтле рационализация тәкъдимнәре бирделәр. Каучукны кул белән кисүне механик рәвештә кисү белән алыштыру турында цех начальнигы урынбасары иптәш Хохлов тәкъдиме шушы көннәрдә производствога кертелде. Бу тәкъдим елына 50 мең сумнан артыграк экономия бирәчәк һәм бу операциядә эшләүчеләр санын 50 процентка кыскартырга мөмкин булачак.

Вакуум-мешалкага каучук төяү эшен уңайлаштыру турында механик иптәш Гордеев тәкъдимен тормышка ашыру буенча хәзерлек эшләре алып барыла. Күп хезмәт сорый торган бу эш элек кулдан башкарыла иде. Иптәш Гордеев тәкъдиме елына 60 мең сум экономия бирәчәк һәм бу эштә эшләүчеләр санын 25 процентка кыскартачак.

(ТатТАСС).

Чит илләрдә

НОРВЕГИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 15 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегия армиясе командованиесе иглан иткән белдерү буенча, Норвегия гаскәрләре сугыштан соң Хенефос шәһәрен ташлап чыкканнар. Германия гаскәрләре Конгсбергны, Ларвикны һәм Сетесдалны алганнар. Тронделагга самолетларга төяп Ослодан Германия гаскәрләре китерелгән.

Сканер таулары районында, Конгсвингердан көньякта каты сугышлар бара. Германия гаскәрләре Ворма елгасын кичеп Эйдсволл шәһәрен алганнар. Алар Швеция чигенә житеп төньякка, Стремстадка таба борылганнар һәм Халден белән Фредрикстадны алганнар.

ЛОНДОН, 15 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Ослога якын гына урында хәрәкәт итүче Германия гаскәрләре ныклы каршылыкка очрыйлар. Сугышлар аерым алганда Ослодан көньяк-көнчыгышта Фредрикстад районында (Осло-Фиордка керү юлында) бара. Швеция матбугатының хәбәр итүенә караганда, немецләр Гломма елгасында Фредрикстадтан төньякта Сарпсборгны алганнар. Норвегия белдерүләрендә Швеция чиге якынындагы Халден шәһәренең әле һаман да норвегиялеләр кулында икәнлеге күрсәтелә. Элегрәк „Дагенс нюхетер“ газетасы бу шәһәр 100 кешедән дә кимрәк булган Германия отрядына каршылыксыз бирелде дип хәбәр иткән иде.

Хәбәр итүләренә караганда, Ослодан төньяк-көнчыгышта Германия гаскәрләре Эйдсволл һәм Конгсвингер районында киң һөҗүмгә хәзерләнеп ныклы басым ясыйлар. Бу һөҗүмнән теләк — Швеция белән тимер юл элемтәсен өзү.

ЛОНДОН, 15 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Англия авиация министрлегенең рәсми белдерүен тапшыра. Бу белдерүдә Англия авиациясе кичә Норвегиянең Германия гаскәрләре алган Ставангердагы аэродромына янадан һөҗүм ясады диелә. Һөҗүм нәтиҗәсендә аэродромдагы күп кенә самолетларга зиан килгән. Англия авиациясе шулай ук Хаф-Фиордка да һөҗүм ясаган. Монда Германиянең күп кенә гидросамолетлары булган. Англия авиациясе аларга пулеметтан аткан. Англия самолетлары Хаф-Фиордта куелган Германия пулеметларын атудан туктарга мәҗбүр иткәннәр.

ЛОНДОН, 15 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең авторитетлы даирәләре Шетланд атауларыннан төньяктарак Англиянең „Глазго“ типындагы крейсерының Германия су асты көймәсе тарафыннан батырылуы турында Германия армиясе верховный командованиесенең кичә иглан ителгән белдерүен юкка чыгаралар.

БЕРЛИН, 15 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге белдерүен тапшыра: „Көньяк Норвегиядә яңа гаскәрләр һәм материаллар килү аркасында 14 нче апрельдә хәл шактый ныгыды. Бу районда диңгездә дошманның әһәмиятле хәрәкәтләре булмады. Нарвикта көн тыныч үтте. Англиянең зур хәрби диңгез көчләре портка керү юлына блокада ясадылар. Бергенда Англиянең 2 самолеты Германиянең сәүдә пароходына бомба ташлап, аны батырды. Аннары Германия истребительләре 2 самолетны да бәреп төшерделәр. Ставангер һәм Кристиансунд районында көн тыныч үтте. 13 нче апрельдә Англия самолетларының уңышсыз һөҗүме вактында Германиянең „Мессершмитт“ истребительләре Англиянең 2 „Виккерс - Веллингтон“ самолетын бәреп төшерделәр. Осло районында Германия гаскәрләре Хенефосны алдылар. Гомумән әйткәндә Осло районында норвегиялеләрнең тупланырга маташулары җимерелде. Немецләр үзләре аз гына югалту ясап күп санда сугыш материаллары кулга төшерделәр. Скагерракта Германиянең кораллы көчләре дошманның тагын 2 су асты көймәсен юк иттеләр. Шулай итеп, соңгы көннәрдә Германиянең диңгез һәм һава көчләре тарафыннан батырылган су асты көймәләренең саны 7 гә житте. Немецләр Норвегиянең „Хваль“ миноносецын тотып алдылар. Аның командасы немецләр белән алмаштырылды. 14 нче апрельдә Германия авиациясе Төньяк диңгез өстендә һәм Норвегиянең бөтен ярлары өстендә разведка очышлары үткәрде“.

БЕРЛИН, 15 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының Ослодан алып хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре, Ослодан көньяк-көнчыгышка таба хәрәкәт итеп һәм Норвегия гаскәрләренең каршылык күрсәтүләрен бастырып, 300 кешене пленгә алганнар, 7 орудие һәм күп санда винтовкалар һәм сугыш кирәк-яраклары кулга төшергәннәр.

БЕРЛИН, 15 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының тапшыруына караганда, Норвегиядән алынган соңгы хәбәрләр буенча, Германия гаскәрләре үзләре алган территорияне киңәйтүне дәвам иттерәләр. Осло районында Германия гаскәрләре Норвегиянең Хенефостагы һәм Конгсбергтагы әһәмиятле сугыш заводларын һәм Фредрикстадтагы ныгытылган зонаны алганнар. Германия гаскәрләрен Норвегия портларына төшерү планлы төстә бара. Әлегә кадәр аерым рәвештә хәрәкәт иткән аерым хәрби берләшмәләр арасында бер кадәр элемтә урнаштырылды.

Германия авиациясе 14 нче апрельдә Төньяк диңгез өстендә һәм Норвегиянең Нарвикка кадәр булган бөтен яр буе өстендә разведка очышлары үткәрде. Нарвик янында ук дошманның хәрби диңгез көчләре күренде, Нарвикның башка урыннарында тыныч. Англиянең хәрби диңгез көчләре Төньяк Норвегиянең аерым фиордларына үтеп керергә һәм анда десант төшерергә маташырлар дип уйларга кирәк.

Балтык диңгезе районнарына миналар кую турындагы хәбәргә откликлар

БЕРЛИН, 15 апрель. (ТАСС). Латвиянең „Ритс“ газетасы Төньяк һәм Балтык диңгезләрендә Мемельгә кадәр миналар куя алулары турында англичаннарның хәбәр итүләрен тәнкыйть итә. Газета болай дип яза: „Англия флотының Скагеррак һәм Каттегат бугазлары аркылы Балтык диңгезенә үтеп керә алуларына ышану шикле. Бу суларга миналарны даниялеләр һәм немецләр куйганнар иде. Миналар куелган урыннарның сакланган вакытта гына әһәмияте бар. Англичаннар өчен исә Балтык диңгезендә, зур һәм кечкенә Бельт бугазларында мондый мөмкинлек булу бик шикле“.

„Лиетувос Айдас“ газетасының хәбәрчесе үз хәбәрен юкка чыгара

КАУНАС, 15 апрель. (ТАСС). Литва телеграф агентлыгы хәбәр итә: „Норвегиядәге сугышлар алдыннан Германиянең диңгез флоты өчен Мурманск гүяки база булган дигән тикшерелмәгән хәбәрләр буенча Литвадагы „Лиетувос Айдас“ газетасының Берлиндәге хәбәрчесе тарафыннан иглан ителгән ялган информация, хәбәр чененең үзе тарафыннан юкка чыгарылды.

ОСЛОДАГЫ ХӘЛ

ОСЛО, 13 апрель. (ТАСС). Газеталар азык белән тәэмин итүне чикләү турында Осло муниципалитетының белдерүен иглан итәләр. Якын арада карточка системасы кертелер дип көтелә. Норвегия матбугаты халыкны азык запасы җыймаска чакыра. Вкладларын алырга теләүче вкладчылар күп булу сәбәпле банклар өч көнгә ябылган. Чит ил кешеләрен кертүне тыю турында Ослода һәм Акерсхуста полицмейстерның бойрыгы иглан ителгән. Шведларга, датчаннарга, финнәргә, исландиялеләргә һәм экстерриториальлек хокуклары булган башка кешеләргә генә бу шәһәрләргә керү рөхсәт ителә. Шушы уңай белән Германия властьлары приказ чыгардылар. Бу приказда чит ил кешеләре турындагы бойрыкны үтәмәүче кешеләр хәрби судка биреләчәкләр, диелә.

Ослодагы немец гаскәрләренең саны шактый артты. Алар мәктәпләргә һәм җәмәгат биналарына урнаштырылганнар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

Үзәк Кытайда. Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләренең Наньчанга һөҗүмнәре дәвам итә. Японнар монда оборона кырылмалары төзиләр һәм кайбер урыннарда каршы һөҗүмгә күчәләр. Ләкин уңышлы нәтиҗәләргә ирешә алмыйлар.

Кытай гаскәрләре шулай ук фронтның Хунань, Хубэй һәм Хэнань провинцияләре чикләрендәге аерым участкыларында да японнарның позицияләренә каршы һөҗүм алып баралар.

Төньяк Кытайда. Шаньси провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытайлар Чжанцзы һәм Хугуаны шәһәрләренә берничә тапкыр атака ясадылар. Шушы ук провинциянең көньяк-көнбатыш өлешендә Датун—Пучжоу тимер юлы секторында да сугышлар бара.

Хәзер билгеле булганча, 2 нче апрельдә кытай партизаннары Бэйпин—Суйюань тимер юлына мина куйганнар һәм Сарачи станциясе янында японнарның хәрби поездын шартлатканнар. Шартлау вактында японнарның 100 солдаты һәлак булган.

* * *

„Шеньчжоужибао“ газетасының кичеккән маглүматларына караганда, 6 нчы апрельдә кытай самолетлары көтелмәгәндә Кантон өстендә күренгәннәр. Япон аэродромына, сугыш әйберләре складларына һәм пристаньгә бомбалар ташланган. Бераздан японнарның 20 самолеты һавага күтәрелгән. Һавадагы сугыш вактында японнарның 2 самолеты бәреп төшерелгән. Шул ук көнне кытай авиациясе отряды Шанхай-Нанкин тимер юлында японнарның сугыш объектларын бомбага тоткан.

15 апрель. (ТАСС).

ФИНЛЯНДИЯ ИЛЧЕСЕ И. К. ПААСИКИВИ ӘФӘНДЕНЕҢ ЫШАНЫЧ ГРАМОТАЛАРЫ ТАПШЫРУЫ

15 нче апрельдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин Финляндиянең гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре И. К. Паасикиви әфәндене кабул итте. Паасикиви әфәнде үзенең ышаныч грамоталарын тапшырды.

Волгада боз ага.

И. Галиев фото-этюды.

В. И. ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ АЛДЫННАН

В. И. ЛЕНИН ӘСӘРЛӘРЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

Татгосиздат 1939 нчы елда В.И. Лениннең 23 исемдәге әсәрләрен татар телендә басып чыгарды. Алар 230 мең тиражда басылдылар.

Бу әсәрләр арасында В. И. Лениннең ике томдагы сайланма әсәрләренең 1 нче томы, „Нәрсә эшләргә?“, „Империализм-капитализмның иң югары стадиясе“ дигән китаплары һәм башкалар бар.

Быел В. И. Ленин әсәрләре татар телендә 270 табак күләмендә басылачак. 59 табак күләмендәге сайланма әсәрләрнең II нче томы һәм „Бер адым алга, ике адым артка“ дигән 12 табаклы китап шушы көннәрдә басылып чыгалар.

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНДА

В. И. Лениннең туувына 70 ел тулу уңае белән Октябрь районында агитаторлар белән консультацияләр һәм беседалар үткәрелә. Фомкино авылында бу эшне партия оешмасы секретаре иптәш Саттаров алып бара. Бу авылдагы уку өендә һәм мәктәптә Ленин әсәрләреннән, Лениннең тормышын һәм иҗадын чагылдыра торган материаллардан күргәзмәләр оештырылды.

22 нче апрельдә Владимир Ильичнең тормышы һәм революцион эше турында колхозларда һәм кыр станнарында беседалар үткәреләчәк.

КЫЗЫЛ АРМИЯ РАЙОНЫНДА

Кызыл Армия районының колхозларында В. И. Лениннең туувына 70 ел тулу көненә ныклы хәзерлек бара. Агитаторлардан Хәбибуллин, Галимов, Сафин иптәшләр Владимир Ильичнең тормышы һәм революцион эше турында „Алга“ колхозында беседалар үткәрәләр. „Марс“, „Комбайн“ колхозларында, Нәриман исемендәге колхозда һәм башкаларда да В. И. Ленин турында беседалар үткәрелә.

ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге 70 еллыкны үткәрү буенча колхозлардагы агитколлективларга материаллар җибәрде. Колхозларда үткәрелә торган җыелышларда докладлар ясау өчен ВКП(б) райкомы партия активыннан 28 кеше билгеләде.

Райкомның парткабинеты В. И. Лениннең тормышын һәм революцион эшен чагылдыра торган материаллардан күргәзмә оештырды. (ТатТАСС).

САБА РАЙОНЫНДА

Саба районы учреждениеләрендә һәм колхозларында Ленин көннәренә зур хәзерлек башланды. ВКП(б) райкомы В. И. Лениннең тормышы һәм революцион эше турында колхозларда докладлар ясау өчен 71 докладчы - беседачы билгеләде. 17 нче апрельдә алар өчен инструктив киңәшмә үткәрелә.

Район парткабинеты Ленин көннәренә карата зур күргәзмә хәзерли.

РАДИО-ТАПШЫРУЛАР

Татарстан Радиокомитеты революция даһие Владимир Ильич Лениннең туувына 70 ел тулу көнендә махсус программа белән Ленинга багышланган тапшырулар бирәчәк. Бу тапшыруларда Лениннең тормышы һәм революцион эше турында доклад-лекцияләр, Ильичнең яшьлек еллары, Казанда яшәгән вакты турында әдәби һәм музыкаль тапшырулар булачак. Татар совет язучылары һәм шагыйрьләре үзләренең Ленинга багышланган әсәрләре белән микрофон алдында чыгачаклар.

Лениннең беренче сөрген урыны булган Ленино (элекке Кокушкино) авылындагы музей-йорттан 21 нче апрельдә трансляция булачак. Бу трансляцияне оештыру өчен Татарстан Радиокомитетының 3 кешелек бригадасы Ленино авылына чыгып китте.

ҮЗЕШЧӘНЛЕК СӘНГАТЕ ОЛИМПИАДАСЫ

Шушы көннәрдә Зеленодольскида үзешчәнлек сәнгате олимпиадасы үткәрелде. Олимпиадада 8 коллектив, байтак кына аерым башкаручылар—барлыгы 235 кеше катнашты. Олимпиада чыгышларын 3 меңнән артык тамашачы карады.

3 нче фанер заводы клубының рус драма түгәрәге А. Островскийның „Гаепсездән гаеплеләр“ пьесасын, Париж Коммунасы исемендәге клубның рус драма түгәрәге Островскийның „Ярлылык—кимчелек түгел“ дигән комедиясен, татар драма түгәрәге Р. Ишмуратның „Ил өчен“ пьесасын куеп, тамашачылар тарафыннан яхшы бәя алдылар.

Бу клубның иптәш Фишкин житәкчелегендәге тынлы оркестры шәһәрдә иң яхшы оркестрлардан санала. Ул олимпиада вактында аерым номерларны сокланырлык итеп үтәде.

Олимпиада кичәләрендә чыгыш ясаган аерым башкаручылардан Жюри комиссиясенең карары буенча 3 нче фанер заводы рус драма түгәрәге, Париж Коммунасы исемендәге клубның рус һәм татар драма түгәрәкләре, шулай ук бу клубның тынлы оркестры һәм аерым башкаручылары республика күләмендәге олимпиадада катнашу хокукын алдылар. Яхшы башкаручылар һәм коллективлар бүләкләнделәр.

И. Файзуллин.

Казан Дәүләт университетының үзешчәнлек сәнгате коллективы шушы көннәрдә 5 нче олимпиада үткәрде. Олимпиада 4 көн дәвам итте. Анда студентлардан һәм фән ни работникларыннан 200 кеше катнашты. Иң яхшы башкаручылар бүләкләнделәр. Иптәш Яковлев житәкчелегендәге рус хоры һәм студент иптәш Зарипов житәкчелегендәге татар драма түгәрәге акча белән бүләкләнделәр.

Значкистлар хәзерләү

Шушы елның 3 ае эчендә Казандагы 14 нче трестның охрана работникларыннан 80 кеше „ПВХО“ значогына, 30 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшырдылар. Значкистлар хәзерләүне тагын да көчәйтү өчен яңадан 8 түгәрәк эшләп килә. Охрана работникларының Осоавиахим оешмасы Татарстан АССР ның XX еллыгы хөрмәтенә значкистлар хәзерләү планын арттырып үтәү өчен көрәшә.

В. Прокофьев.

Балалар өчен яңа постановкалар

Казандагы Яш Тамашачылар театры халыкара пролетариатның бөек бәйрәме—1 нче Майга яңа постановкалар хәзерли.

Бәйрәм көннәрендә балалар театр сәхнәсендә А. Карельскаяның „Әби“ исемле 3 пәрдәлек комедиясен күрәчәкләр.

1 нче Май алдыннан һәм бәйрәм көннәрендә шулай ук „Доктор Калюжный“ дигән пьеса да куелачак.

Театр коллективы бәйрәм вактында Культура сараена һәм шулай ук Зеленодольскигә, Юдиногә барып күчмә спектакльләр бирәчәк.

Беренче һәм 2 нче майда театр тарафыннан икешәр спектакль куелачак. Бәйрәм вактында 3.000 гә якын балага хезмәт күрсәтергә уйланыла.

ПИОНЕР ЛАГЕРЬЛАРЫ

Казанның Бауман районында пионерларны һәм мәктәп балаларын лагерьларга чыгаруга хәзерлек бара. Быел бу районнан лагерьларга барлыгы 2.125 бала җибәреләчәк.

Район күләмендәге лагерь Лопатино станциясе янында оештырыла. Балаларны урнаштыру өчен Волгадан ерак булмаган нарат урманы янында биналар хәзерләнде.

Язу машиналары заводы эшчеләренең һәм хезмәткәрләренең балалары өчен Кече Дербышка авылында 150 кешелек лагерь ачыла. Икмәк пешерү предприятиеләрендә эшләүчеләрнең балалары Зәңгәр күл янындагы лагерьга җибәреләләр. Анда ике сменада 250 бала ял итәчәк.

Җирле промышленность предприятиеләрендә

Татарстан Җирле Промышленность Халык Комиссариаты предприятиеләре быел 46 миллион 800 мең сумлык товар эшләп чыгаралар. Кин куллану һәм хуҗалык товарларын житештерү шактый арта. 590 мең сумлык мебель эшләнәчәк.

Оек бәйләү, кием тегү, шулай ук киемнәрне төзәтү өчен Казанда һәм районнарда яңа мастерскойлар ачыла. Районнардагы мастерскойлар 400 мең сумлык трикотаж товарлары эшләп чыгаралар.

ТАТАРСТАНДА

Быел Татарстанда пожар деполары салу, пожар инвентарьлары алу һәм пожар дружиналарына начальниклар хәзерләү өчен Госстрахтан 1 миллион 600 мең сум акча билгеләнде. Узган ел шул ук эшләргә 1 миллион 162 мең сум бирелгән иде.

Татарстанның күн һәм мех промышленносте өчен җәй башында каеры хәзерләүне оештыру чаралары күрелә. Быел Татарстан урманнарында 3.900 тонна тал, имән каерысы, 1.100 тонна чыршы каерысы хәзерләнәчәк.

Буденный районының Кече Чынлы авылында авыл советы өчен ике катлы йорт салынды. Йортның аскы этажына 200 урынлы уку өе, өске этажына авыл советы башкарма комитеты, сельпо конторасы, почта бүлеге һәм парткабинет урнаштырылды.

Кызыл Армия районының Нәриман исемендәге колхозында яңа мәктәп төзелде. Аны төзү өчен 35 мең сум расход тотылды. Бу акчаның 12 мең сумын колхоз бирде. Яңа мәктәптә укулар башланды.

БАЛАЛАР ӨЧЕН МӘЙДАНЧЫКЛАР

Кыр эшләре вактында колхозларда балалар өчен мәйданчыклар ачуга хәзерлек бара.

Наркомпрос планы буенча быел Татарстан колхозларында 80 мең бала өчен 2.010 мәйданчык оештырылырга тиеш. Балалы хатыннарның язгы чәчү эшләренә катнашуларын тәэмин итү өчен мәйданчыкларның бер өлеше яз көне үк оештырылачак.

Узган ел Шөгер, Чүпрәле, Алабуга, Бөгелмә районнарында һәм алдынгы башка районнарда мәйданчыклар оештыру планы арттырып үтәлде. Нәтиҗәдә мәйданчыкларда 91 мең бала тәрбияләнде. Шул ук вакытта Әлки, Бондюг һәм Тельман районнары мәйданчыклар оештыру планнарын үтәмәделәр.

Шөгер һәм Бөгелмә районнарында быел да мәйданчыклар оештыруга хәзерлек яхшы бара. Шөгер районында 2.000 бала өчен 40 мәйданчык оештырыла. Мәйданчыклар өчен мебель, уенчык, савыт-саба һәм башка әйберләр хәзерләнде.

КОЛХОЗ-СОВХОЗ ТЕАТРЫ КОЛХОЗЛАРДА

Татарстан Сәнгать Эшләре Идарәсенең Минзәлә районындагы колхоз-совхоз театры язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрү вактында колхозларга культура хезмәте күрсәтү өчен районнарга чыгып китте. Театрның икенче бригадасы Калинин, Тымытык, Азнакай, Мөслим, Әлмәт, Сарман һәм Ворошилов районнарының колхозларында 50 постановка куя. Тымытык, Мөслим һәм Калинин районнарының күп кенә колхозларында постановкалар бирелде инде. Шушы көннәрдә Азнакай районының „Туры юл“ һәм „Сарсаз“ колхозларында спектакль бирелеп, тамашага „Бакчалар чәчәк ата“ пьесасы куелды.

С. Хафизов.

Елгаларда

Волга суы 16 нчы апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 70 сантиметр, Вязовые янында 144 сантиметр, Югары Ослан янында 128 сантиметр артты. Югары Ослан янында арткан бөтен суның биеклеге 5 метр 38 сантиметрга житте. Горькийдан алып Сталинградка кадәр көчле рәвештә боз ага.

Кама суы Молотов шәһәре янында 39 сантиметр, Красный Бор янында 46 сантиметр, Алабуга янында 26 сантиметр, Лаеш янында 10 сантиметр артты. Молотов шәһәреннән алып Лаешка кадәр боз ага.

Вятка суы Медведки янында 31 сантиметр, Мамадыш янында 47 сантиметр артты. Мамадыш янында боз агып тора.

Ока елгасының югары ягыннан алып Касимга кадәр боз агып бетте. Бер тәүлек эчендә Муром янында 65 сантиметр, Горький янында 60 сантиметр су артты. Елатьмадан алып Горькийга кадәр боз ага.

БЕЛДЕРҮ

Бүген, 17 апрельдә, кич сәгать 6 да, язучыларның Г. Тукай исемендәге кабинетында иптәш И. Н. Фирсовның „Казан ханлыгы“ турында лекциясе була.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ТӨТЕН ЮЛЛАРЫН ҺӘМ ПЕЧЬЛӘРНЕ КОРЫМНАН ЧИСТАРТУ ТУРЫНДА ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘҖБҮРИ КАРАРЫ № 3

1940 нчы ел, 27 нче март.

Пичләрдә һәм төтен юлларында корымга ут кабынудан пожар чыгуларны булдырмау теләге белән, Казан шәһәр Советы Башкарма Комитеты карар бирә:

1. Төтен юллары һәм печьләр корымланудан түбәндәге тәртиптә чистартылып торырга тиеш:

а) русский печьләр, кухня плитәләре, самовар һәм кипятильник куела торган төтен юллары—бөтен ел буена һәр ике айда бер тапкыр;

б) махсус печьләр, икмәк пешерү печьләре, кондитер әйбере пешерү печьләре, сушилка, кипятилка, прачка һәм мунча печьләре—бөтен ел буена һәр айда ике тапкыр;

в) Голландский һәм Утермаковский печьләр, каминнар, калориферлар, үзәк ягу-җылыту системасы печьләре—бөтен ягу сезонында һәр ике айда бер тапкыр.

2. „Казгорстрой“ трестын—барлык йорт хуҗаларының, үзләренең йортларындагы печьләрне һәм төтен юлларын чистартып торуларын тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

Йорт идарәләрен,—печьләрне һәм төтен юлларын чистарту буенча, „Казгорстрой“ тресты белән договор төзәргә мәҗбүр итәргә.

3. Бу мәҗбүри карарның үтәлешен күзәтү Шәһәр Янгын сакчылыгына һәм коммуналь хуҗалык органнарына йөкләтелә.

4. Бу мәҗбүри карарның 1 нче пунктын бозуда гаепләнүче кешеләр административ җаваплылыкка: 100 сумга кадәр штрафка яисә 30 көнгә кадәр мәҗбүри хезмәткә тартылалар.

5. Бу мәҗбүри карар, иглан ителгән көннән алып, 15 көннән соң үз көченә керә һәм Казан шәһәре территориясендә 2 ел буена гамәлдә булып санала.

Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты.

СССР Госпланы Халык Хуҗалыгы Учеты Үзәк Идарәсенең
УКЫТУ КОМБИНАТЫ
производстводан аерып укытып, киләчәктә Ленин районы территориясендәге заводта эшләү өчен Казанда
ХИСАПЧЫЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ КУРСЛАРЫ АЧА
Курсларда укучыларга, аларның академик өлгерешләренә карап, айга 150 сумнан 225 сумга кадәр күләмендә стипендия бирелә. Уку срогы алты ай.
Курсларга 17 дән 25 кә кадәр яштәге, кимендә 7 класс күләмендә белемле һәм Казанда даими тору урны булган кешеләр алыналар.
Гаризалар Укыту комбинаты канцеляриясендә һәр көн иртән 9 сәгаттән көндез 3 кә кадәр алына. Казан, Чернышевский урамы 11. 621—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 17 нче апрельдә
КЫЮ КЫЗЛАР
Иртәгә, 18 нче апрельдә көндез һәм кич
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгаттә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
19 һәм 25 нче апрельдә Зур театр бинасында
ФАУСТ
21 нче апрельдә
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Кич 8 сәгаттә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген зур программада
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ ДӘВАМ ИТӘ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Иртәгә, 18 нче апрельдә
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уеннар: көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 17 нче апрельдә һәм иртәгә кич
ПРЕМЬЕРА
МЕТЕЛЬ
18 нче апрельдә көндез
МАСКАРАД
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КИРӘК:
Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына, даими эшкә ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР һәм ХИСАПЧЫЛАР. Казан, Кремль 3 нче подъезд. 635—1

Тарловка санаториенда даими рәвештә эшләү өчен ТУБЕРКУЛЕЗ ВРАЧЫ һәм МЕДСЕСТРА. Шартлары турында белешү өчен адрес: Казан, Комлев урамы, Хезмәт сарае, ВЦСПС ның Ял йортлары һәм Санаторийлар Татарстан идарәсе (28 нче бүлмә). 608—3—3

Росглавхлеб Татарстан трестының транспорт базасына даими эшкә РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ ХИСАПЧЫСЫ, ТАКСИРОВЩИК, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ, ТОКАРЬЛАР һәм СЛЕСАРЬЛАР. Казан, Колхоз урамы, 20. 609—2—2

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ГРОЗА
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ЯҢА ЗАМАННАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1388. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1464.